
# ТАТАРСТАН



# БЕЗ БЕРГӘ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА 170 ТӘН АРТЫК МИЛЛӘТ ВӘКИЛЕ ЯШИ

Татарлар
Руслар
Чувашлар
Удмуртлар
Мордвалар
Марилар
Украиннар
Башкортлар
Азәрбайҗаннар
Үзбәкләр
Әрмәннәр
Таҗиклар
Белоруслар
Еврейлар
Алманнар
Казахлар
Грузиннар
Кыргызлар
Молдаваннар
Төрекмәннәр
Кореялылар
Лезгиннар
Чегәннәр
Төрекләр
Греклар
Поляклар
Чеченнар
Осетиннар
Коми-пермяклар
Аварлар
Даргиннар
Вьетнамнар
Литвалылар
һәм башкалар







УДК 39(470.41)
ББК 63.529(2Рос.Тат)
Т 23

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТ

ISBN 978-5-6046009-4-8

© Татарское детское издательство, 2022

# ТАТАРСТАН

# БЕЗ БЕРГӘ

КАЗАНЬ
2022

# КАДЕРЛЕ ДУСТЫМ!

Татарстан халыкларының мәдәнияте – республикабызның олы байлыгы, чөнки ул 170 тән артык халыкның мәдәнияте.

Синең алдыңда уникаль китап. Бу Татарстанның иң күп санлы халыклары – руслар, татарлар, чувашлар, удмуртлар, мордва һәм мариларның күптөрле һәм гаҗәеп мәдәни дөньясына сәяхәт.

Син бу халыкларның тормышы һәм көнкүреше турында күп нәрсә белерсең, аларның мәдәни гореф-гадәтләре һәм традицияләре, теле, музыкасы, милли ризык һәм



киемнәренең үзенчәлекләре никадәр кабатланмас һәм гүзәл икәнлеген күрерсең. Шул ук вакытта син барлык халыкларга хас уртаклыкның да булуын белерсең. Аларны тарих, кунакчыллык һәм өлкәннәрне ихтирам итүгә нигезләнгән уртак традицияләр һәм, әлбәттә инде, ата-бабалары яшәгән җир – аларның бөек Ватаны – Россия берләштерә.

Татарстан халыклары күп гасырлардан бирле бергә, бер-берсен хөрмәт итеп, килешеп, дус-тату яшиләр. Безнең көчебез һәм горурлыгыбыз шушы бердәмлектә.



# Милли бизәкләр һәм орнаментлар

Бик борынгы заманнарда, әле язу булмаган вакытларда, кешеләр әйләнә-тирә предметларга, аерым мәгънә салып, гади бизәкләр һәм орнаментлар ясаган.

Гасырлар узу белән, бизәкләр күпкә катлаулырак һәм төрлерәк була барган. Нәкъ элеккечә, төрле символларга тылсым көче биреп, хәзер алар белән йортларны, көнкүреш әйберләрен, киемнәрне бизиләр.


Бизәк ул – сызык һәм фигуралардан торган сурәт. Бизәк рәсемен теләсә нинди тәртиптә урнаштырырга мөмкин.

Бизәкләрне кеше генә түгел, табигать тә барлыкка китерә ала. Мәсәлән, тәрәзәләрдә кышкы могҗизалы бизәкләрне синең бик күп тапкырлар күргәнең бардыр.





Татар бизәге




Татар орнаменты

Орнамент – аерым детальләр чиратлаша һәм кабатлана торган бизәк ул.

Орнамент төрле предметларны бизәү өчен хезмәт итә. Безгә латин теленнән кергән әлеге сүз үзе дә «бизәк» дигәнне аңлата.

ORNAMENTUM (лат.)

**МИЛЛИ БИЗӘКЛӘР**
**ҺӘМ ОРНАМЕНТЛАР**





Мари орнаментында атлар сурәтләнеше



Чуваш орнаментында ат сурәтләнеше

Халык орнаментлары традицион символлардан тора. Һәр халыкта ул аерым. Шуңа да карамастан, мәгънәсе белән төрле милләт кешеләренә якын һәм аңлаешлы булганнары да бар.

Кешеләр көндәлек тормышта үзләрен уратып алган әйберләрне – кояш, күк йөзе, чәчәк; ат, үрдәк, әтәч һ. б. йорт хайваннарын сурәтләгән. Халыкларның күп гасырлар дәвамында яхшы күршеләр булып яшәүләре дә мәдәни традицияләр алмашуга ярдәм иткән. Менә шуңа күрә Идел буе халыкларының орнаментлары үзгә булса да, охшашлыклар да бар.



Кояш символы.
Мордва бизәге



Кояш символы.
Рус бизәге



Кояш символы.
Чуваш бизәге



Кояш символы.
Мари бизәге

# РУС ОРНАМЕНТЛАРЫ

Әгәр дә рус орнаментларына игътибар белән карасаң, аларда кызыл һәм ак төсләрнең еш кулланылуын күрергә мөмкин. Андый сайлау очраклы түгел.

Осталар бу төсләргә аерым бер мәгънә биргән.



Тормыш агачы



Галәм символы
(Алатырь йолдызы)



Бәхет символы





Рус орнаментлары

Кызыл төс ул – яшәү, ут, кояш төсе. Кызыл төстәге орнаментлар изге саналган, аларда тылсымлы дәвалау көче бар дип уйлаганнар. Шуңа күрә андый орнаментлы әйберләрне талисман буларак кулланганнар.

Ак төс ул – чисталык һәм азатлык төсе. Ак төстәге символларны кара көчләрдән саклану чарасы буларак файдаланганнар.

19 нчы гасырга кадәр, орнамент һәм бизәкләр җете төстә булсын өчен, табигый буяулар кулланганнар.



# ТАТАР ОРНАМЕНТЛАРЫ

Татар орнаментлары үзләренең төрлелеге һәм күп төстә булуы белән аерылып тора.

Борынгы заманнардан ук татар орнаментларында чәчәк һәм үлән мотивлары чагылыш тапкан. Еш кына осталар канәфер, кыңгырау, мәк, ромашка кебек чәчәкләрнең сурәтләрен кулланган.



Татар орнаментында канәфернең сурәтләнеше



Татар орнаментында кыңгырауның сурәтләнеше



Татар орнаменты

Татар бизәкләрен башка халыкларның орнаментларыннан контурлары буенча җиңел аерып була.


Гөлчәчәк, лалә, кашкарый сурәтләренә аерым мәгънә бирелгән.



Гөлчәчәк – матурлык һәм мәхәббәт символы



Лалә – яңарыш символы



Кашкарый – озак яшәү символы




Күренекле галим, этнограф, тарихчы һәм археолог Карл Фукс: «Татар хатын-кызлары кул эшләренә бик оста: алар эшләгән эскәтер, яулык һәм сөлгеләр гаҗәеп матур», – дип билгеләп үткән.




# ЧУВАШ ОРНАМЕНТЛАРЫ

Буяу һәм фигураларның чын матурлыгын сез чуваш халык бизәкләре һәм орнаментларында таба алырсыз. Юкка гына Чувашияне «йөз мең чигеш һәм йөз мең бизәк ягы» дип атамыйлар.






Сигезпочмаклы йолдыз – кояш символы




Чуваш орнаменты

Чувашларның халык орнаментларында осталар төрле мәгънә белдерә торган квадрат, өчпочмак, зигзаг һәм башка геометрик фигураларны еш кулланалар.



«Тормыш агачы» бизәге




Чуваш бизәкләренең традицион төсләре

# УДМУРТ ОРНАМЕНТЛАРЫ

Бизәк һәм символлар удмуртлар тормышында зур роль уйнаган. Алар аша кешеләр үзләренең дөньяны аңлауларын, табигать белән бәйләнешләрен, хыялларын белдергән, илаһи көчләргә мөрәҗәгать иткән.




Зигзаглы ромб – дуслык символы



Ат – хезмәт сөючәнлек символы



Кояш – яшәү символы




Удмурт бизәкләрендә төсләрнең традицион ярашуы





Удмурт орнаменты

Образларның байлыгы һәм төрлелеге бүген дә этнограф һәм археологларны гаҗәпләндерә. Удмурт бизәкләрендә хайван, кош, чәчәк, йолдыз, планета образларын күрергә була. Һәрбер символ үзенең эчке мәгънәсенә ия. Мәсәлән, теге яки бу нәселгә карау, сәламәтлек, уңыш, уңдырышлылык, яклау символлары.


Үрдәк символы


Йолдыз символы


Ай символы


«Атлар» символы


«Тормыш агачы» символы


Аккош символы

# МОРДВА ОРНАМЕНТЛАРЫ

Мордва халыкларының иҗаты табигать белән тыгыз бәйләнгән. Кояш, чәчәк, агач, елга, кош, хайван образлары халык бизәкләре һәм орнаментларында еш очрый.



Зигзаг – су символы



Квадрат һәм ромблар – муллык һәм уңдырышлылык символлары



Мордва орнаменты

Ата-бабаларның белемнәре «шифрланган» символлар, сакланып, буыннан буынга күчә бара. Шул сәбәпле без бүген күп гасырлар элек яшәгән кешеләрнең ничек гомер иткәннәрен, нәрсә турында хыялланганнарын, аллалардан нәрсәләр сораганнарын белә алабыз.



Сигезпочмаклы йолдыз – кояш символы



Мөгез рәвешендәге бизәк – үлән һәм агачлар символы



Мордва бизәкләренең традицион төсләре

# МАРИ ОРНАМЕНТЛАРЫ

Башка халыкларлардагы кебек үк, мари бизәкләрендә дә тирән мәгънә яшеренгән, аларның бер өлеше явыз көчләрдән яклау буларак хезмәт иткән.



Яхшылык һәм уңдырышлылык символы, бөти



«Өй каравылчысы» символы



Агач, яшәеш башлангычы символы



Мари орнаменты


Һәрбер сызык, һәрбер бөтеркә үз мәгънәсен белдерә һәм безгә бик күп кызыклы әйберләр турында «сөйли» ала, ә бергә кушылган символлардан торган бизәк тулы бер тарих яки әкиятне тапшырырга мөмкин.



Ат – хезмәт сөючәнлек
һәм муллык символы



Күбәләк – җиңеллек
һәм нәфислек символы



Мари бизәкләренең традицион төсләре




# Милли киемнәр

Милли кием – халык мәдәниятенең мөһим өлеше. Элек кешенең ничек киенүенә карап, аның милләте, яше, шөгыле, баймы яки ярлымы икәнлеге турында белеп булган.

Бигрәк тә хатын-кызларның киеме җете төсләре белән аерылып торган. Һәрвакыт матур киенеп йөрсеннәр дип, кызларны бала чактан ук тегәргә һәм чигәргә өйрәткәннәр. Халык костюмнары милли чигешләр белән бизәлгән.

Ир-атлар костюмы хатын-кызларныкы кебек бизәкле булмаган. Гадәттә милли орнамент белән ир-атларның puталары гына бизәлгән.





Хәзерге вакытта көндәлек тормышта беркем дә милли киемнән йөрми. Аларны бары тик музейларда, халык җыр һәм бию ансамбльләре артистларында гына күрергә мөмкин. Әмма соңгы вакытта киемнәрдәге милли мотивлар модада. Хәзерге заман дизайнерлары киемнәрне милли стильдә тегә һәм аларны бизәү өчен еш кына халык бизәкләрен һәм орнаментларын куллана.








# РУС МИЛЛИ КИЕМЕ

Ир-атлар күлмәгендә кыйгач яка һәм хатын-кызларда сарафан рус халык киеменең аерым бер үзенчәлеге булып тора.



Билбау



Тасма



Алъяпкыч



Рус гүзәлләре йөзек һәм муенсалар тагарга яраткан, ә башларына кокошник кигән, асма бизәк – рясна таккан.





Кафтан



Сарафан



Күлмәк



# ТАТАР МИЛЛИ КИЕМЕ

Татар костюмнары башка төрки халыклар костюмнарына охшаган. Төп кием ул – киң күлмәк һәм чалбар. Күлмәк өстеннән хатын-кызлар – камзул яки алъяпкыч, ә ирләр халат кигән.



Түбәтәй



Калфак





Күлмәк



Ыштан

Татар кызларын хәситә (төрле тәңкә, кыйммәтле ташлар, сәдәфләр белән бизәлгән тукыма бәйләвеч) бизәгән. Хәситәне кыз бала өчен аның туган көненнән җыя башлаганнар. Татар гүзәлләре чулпы (чәч толымына кушып үрелгән тәңкәләр) тагып йөргән.







Камзул



Читек



Күлмәк

# ЧУВАШ МИЛЛИ КИЕМЕ

Чуваш халык костюмының нигезе – ирләрдә кыска, хатын-кызларда озын күлмәк. Аның өстеннән алъяпкыч, кафтан яки халат кигәннәр. Бәйрәм киемнәрен мул итеп чигеш белән бизәгәннәр.



Тухья



Күлмәк



Алъяпкыч



Билбау



Чуваш хатын-кызларының башында һәрвакыт сәйлән һәм тәңкәләр белән бизәлгән конуссыман башлык – тухья балкыган. Традиция буенча, кияүгә чыкмаган кызлар очлы башлы тухья кигән, ә кияүдәге ханымнарның милли баш киеме очлы булмаган.



Кафтан



Ыштан



# УДМУРТ МИЛЛИ КИЕМЕ

Удмурт милли киеме – чын сәнгать әсәре.

Удмуртлар озын күлмәк – дэрем кигән. Өске якка хатын-кызлар – алъяпкыч яки халат, ирләр кафтан кигән.



Күлмәк



Билбау




Күкрәк бизәнү әйбере



Удмурт чибәркәйләре тәреләр белән бизәлгән баудан муен бизәнгече – монисто таккан.





Айшон



Сюлык



Оек



Алъяпкыч



# МОРДВА МИЛЛИ КИЕМЕ

Мордва халыкларында, кагыйдә буларак, милли кием чигеш һәм бизәнү әйберләренең күплеге аркасында бик авыр булган. Бу бигрәк тә хатын-кызга кагылган. Мондый киемне киеп йөрү үзе бер сәнгать саналган.

Мукшы һәм эрзяларның милли киемнәрендә аерымлыклар бар.



Күлмәк







Ыштан

Мордва кызлары чигә бизәнгече – ак йоннан эшләнгән шарлар – сергтлар таккан. Кызларның шулай ук кабырчык, чигеш һәм төсле сәйләннәр белән бизәлгән итәк бәйләвече – пулокаркс та булган.





Панго



Пулокаркс
(итәк бәйләвече)




Билбау




# МАРИ МИЛЛИ КИЕМЕ

Мари милли киеменең төп детале булып, күлмәк һәм ыштан саналган. Ирләр күлмәге хатын-кызларныкына караганда кыскарак тегелгән, аның бизәлеше дә матуррак булган.

Күлмәк өстеннән мари хатын-кызлары алъяпкыч һәм кафтан кигән.



Шымакш



Теркупш



Билбау



Марилар этник яктан берничә төркемгә – тау, болын, төньяк-көнбатыш һәм көнчыгыш мариларына бүленә.

Мари хатын-кызларының милли киемен тәңкә, ялтыравык һәм сәйләннәр белән бизәлгән тукымадан ясалган күкрәкчә – яга бизәгән.





Яулык



Күлмәк

# Милли телләр һәм әдәбият

Милли тел – теләсә кайсы халыкның иң зур байлыгы. Анда милли мәдәният һәм милли характер чагылыш таба.

Татарстан Республикасында ике дәүләт теле бар – рус һәм татар телләре.

Тел – мәдәни мирасның бер өлеше, ул безгә ата-бабалардан калган.



Туган телеңне белү – үз илеңнең чын гражданины булу дигән сүз.

Һәр татарстанлының үз туган телен өйрәнү мөмкинлеге бар. Казандагы Халыклар Дуслыгы йортында Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе эшли. Анда төрле милләт кешеләре туган телләрен, үз халкының мәдәниятен, шулай ук башка халыкларның мәдәниятен өйрәнә.












Халыклар Дуслыгы йортының якшәмбе мәктәбе бүлекләрендә түбәндәге телләр өйрәнелә:

| | | |
|---|---|---|
| азәрбайҗан | иврит | рус |
| ассирия | мари | таҗик |
| әрмән | мордва | татар |
| башкорт | немец | удмурт |
| грек | осетин | украин |
| грузин | поляк | чуваш |

# РУС ТЕЛЕ

Рус теле дөньяда иң күп таралган телләр исәбенә керә. Белоруссия, Казахстан, Кыргызстан кебек илләрдә рус теле дәүләт телләренең берсе булып тора.

Рус теле ярты миллионнан артык сүз запасын туплаган иң аһәңле һәм бай телләрнең берсе санала.



Бертуган Кирилл һәм Мефодий – славян мәгърифәтчеләре, рус теле һәм 100 дән артык телнең язуына нигез булган славян әлифбасы – кириллицаны төзүчеләр.



**Александр Сергеевич Пушкин** – күренекле рус шагыйрьләре һәм язучыларыннан берсе. Ул – хәзерге рус әдәби теленә нигез салучы. Аның әсәрләре дөньядагы күп телләргә тәрҗемә ителгән һәм дөнья әдәбияты классикасы санала.

Халык сынамышлары, үткен язмалар, гаиләгә, дуслыкка мөнәсәбәт, кыюлык, кешелеклелек кебек сыйфатларга дан җырлау **халык мәкальләрендә** чагылыш таба. Шул сәбәпле Татарстанның төрле халыкларында мәкальләр бик охшаш.

Мәкальләрдә борынгы ата-бабаларыбызның табигатьне күзәтүләре, гасырлар дәвамында җыелып килгән хыял-өметләре көзгедәге кебек чагылыш таба.

## РУС МӘКАЛЬЛӘРЕ

Тырышкан табар,
ташка кадак кагар.



Эш беткәч, уйнарга ярый.



Арбаны – кыштан,
чананы җәйдән әзерлиләр.



Йөз сум акчаң булганчы,
йөз дустың булсын.



# ТАТАР ТЕЛЕ

Татар теле – Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең берсе. Татар теле Татарстанда иң киң таралган һәм сөйләшүчеләрнең саны буенча Россиядә икенче милли тел санала.

Татар теле төрки телләр төркеменең Идел буе-кыпчак төркемчәсенә карый.



Татар теленең хәзерге заман алфавиты кириллицага нигезләнгән, аңа өстәмә «ә», «Җ», «ң», «ө», «Ү» һәм «һ» хәрефләре кертелгән.



Изучай татарский вместе с героями мультфильма «Алты хәреф»!



Татар халкының яраткан шагыйре – **Габдулла Тукай.**

Татар әдәби теленә нигез салып, Тукай татар мәдəниятен үстерүгә зур өлеш керткән. Татарстанда татар әдәбиятының күренекле классигын олылыйлар, 26 апрель – шагыйрьнең туган көнен республикабыз халкы Туган тел көне буларак билгеләп үтә.

Шагыйрь, беренчеләрдән булып, балалар өчен әдәби әсәрләр яза башлаган. Алар арасыннан иң атаклылары – «Шүрәле» һәм «Су анасы». Туган якка һәм туган телгә мәхәб-бәт белән сугарылган бу искиткеч әкиятләрне инде ничә буын белә һәм яратып укый.



«Шүрәле»
поэмасы геройлары

# ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕ

Кешегә чокыр казыма –
үзең төшәрсең.



Ачның ачуы яман.



МИЛЛИ ТЕЛЛӘР һӘМ ӘДӘБИЯТ

# ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕ

Киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар.



Алма агачыннан ерак төшми.



# ЧУВАШ ТЕЛЕ

Чуваш теле – чувашларның милли теле. Чуваш алфавиты да, башка Идел буе халыкларының алфавитлары кебек үк, кириллицага нигезләнә. Анда үзенчәлекле «Ă», «Ĕ», «Ç», «Ӳ» хәрефләре бар.



Чуваш теле – болгар теле төркеменең бердәнбер тере теле.



**Иван Яковлевич Яковлев** – хәзерге заман чуваш әлифбасын төзегән мәгърифәтче. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Иван Яковлевич үз халкына хезмәт иткән: балаларга чуваш телендә белем бирә торган халык мәктәпләре ачкан, чувашлар өчен чуваш һәм рус телләре дәреслекләре төзегән. Иван Яковлевның тырышлыгы нәтиҗәсендә чувашлар үз милли телләрендә китаплар чыгару мөмкинлегенә ия булган.



Борынгы заманнардан ук күп буыннар тарафыннан тупланган халык зирәклеге һәм тәҗрибәсе мәкаль һәм әйтемнәр аша тапшырылган.

## ЧУВАШ МӘКАЛЬЛӘРЕ

Дуслары булмаган кеше тамырсыз агач кебек.



Кешеләрдән аз ал, күп бир.



# ЧУВАШ МӘКАЛЬЛӘРЕ

Яхшы дан байлыктан да кыйммәтрәк.




Ышанычлы дус бәяләп бетергесез.



# УДМУРТ ТЕЛЕ

Удмурт теле – удмуртларның милли теле. Удмурт теле, татар теле кебек үк, сүзләрдә басымның соңгы иҗеккә төшүе белән аерылып тора. Телдә рус һәм татар телләреннән кергән алынма сүзләр күп.

Удмурт алфавитында да үзенчәлекле хәрефләр бар: «Ӝ», «Ӟ», «Ӥ», «Ӧ», «Ӵ».



**Кузебай Герд** – удмурт әдәбияты классигы һәм удмурт балалар әдәбиятына нигез салучы, шагыйрь һәм язучы. Ул балалар өчен 80 шигырь һәм 50 дән артык хикәя язган. Кузебай Герд «Муш» («Бал корты») дип аталган беренче удмурт бала-лар журналы оештырган һәм аның мөхәррире булган.

Мәкаль кайчак халык турында хәтта иң зур күләмле әсәргә караганда да күбрәк сөйли.

# УДМУРТ МӘКАЛЬЛӘРЕ

Иң авыр эш – эшсезлек.



Сусыз мичкә дә кибә.



Кеше акылы белән озак яшәп булмый.



Халык эшли – син дә эшлә, халык бәйрәм итә – син дә бәйрәм ит.



# МОРДВА ТЕЛЛӘРЕ

Мордва телләре – мукшы һәм эрзя халыклары телләре.

Ике телнең дә Урал телләре семьясының бер үк телләр төркеменә керүенә карамастан, аларда аерымлыклар шактый. Мәсәлән, исем һәм фигыльләр төрләнгәндә, бу телләрдә төрле кушымчалар ялгана. Шуңа күрә мукшы һәм эрзя һәрвакытта да бер-берсен аңлап бетермәскә мөмкин.



**Михаил Лукьянович Сайгин** – мукшы халык язучысы, балалар китаплары һәм авылда яшәүчеләрнең тормышы турында танылган әсәрләр авторы. Аның китаплары рус, мари, чуваш, карел, удмурт һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән.



**Василий Кузьмич Радаев** – эрзя халык шагыйре, прозаик, шул исемдәге мордва герое турындагы «Сияжар» халык эпосы авторы. Бу әсәргә материалны Василий Кузьмич бөтен гомере буена диярлек җыйган. Поэма мордва халыклары-ның хикәятләре нигезендә язылган.


Халык мәкальләре – һәр халык мәдәниятенең мөһим элементы. Алар буыннан буынга тапшырыла һәм кешелекле, дус, кыю, зирәк булырга өйрәтә.

# МОРДВА МӘКАЛЬЛӘРЕ

Ботаксыз – агач түгел,
баласыз – гаилә түгел.



Эш турында сөйләү җиңел,
эшләве авыр.



Туган якка юл да киң.



Ата-ана бәхете –
бала бәхетендә.



# МАРИ ТЕЛЕ

Мари теле элек чирмеш теле дип йөртелгән: мариларның элеккеге атамалары – чирмешләр.

Марилар берничә этник төркемгә бүленгәнлектән, аларның вәкилләренә төрле сөйләшләр хас: тау, төньяк-көнбатыш, көнчыгыш һәм болын мари телләре.

Төрле тел төркемчәләрендә булган марилар, әлифбалары туры килмәсә дә, бер-берсен яхшы аңлыйлар. Мәсәлән, болын мари телендә тау мари телендә булмаган «Ҥ» хәрефе бар. Аның каравы тау мари телендә башка телләрендә очрамый торган «Ӹ» хәрефе бар.



**Ким Кириллович Васин** – мари язучысы, педагог, әйдәп баручы әдәбият белгечләренең берсе, Мари Эл Республикасының халык язучысы. Рус язучыларының күп әсәрләрен мари теленә тәрҗемә иткән, энциклопедияләр төзүдә катнашкан.



Халык мәкальләрендә күп буыннарның зирәклеге туплан-ган. Бер җөмләгә борынгы ата-бабаларыбыздан килгән тирән мәгънә сыйган.

# МАРИ МӘКАЛЬЛӘРЕ

Аю үз өнендә көчле.



Ялган сүз – өч көнгә,
дөрес сүз – гасырларга.



Өлкән кеше сүзе –
көмеш тәңкә.




Атсыз хуҗалык
башсыз кеше кебек.



# Күренекле шәхесләр

Һәр халыкта туган җирен, халкын үзенең хезмәте, таланты яки батырлыгы белән данлаган кешеләр бар.



**Иван Иванович Шишкин** – күренекле рус рәссамы. Алабугада туган. Иван Шишкин туган ягының әкияти матурлыгы сурәтләнгән пейзажлары белән дөньякүләм танылуга ирешкән. «Нарат урманында иртә», «Кораб урманы», «Арыш» һәм башка күп кенә картиналары Третьяков галереясында һәм Россиянең башка танылган музейларында саклана.




Шишкинның «Кораб урманы» картинасы. 1898 ел.



Шишкинның «Арыш» картинасы. 1878 ел.

**Фёдор Иванович Шаляпин** – үзенең таланты белән дөнья опера сәнгатенә зур йогынты ясаган бөек рус опера җырчысы. Артистның таланты яшьли ачылган. Казан шәһәрендә ярлы гаиләдә туган Фёдор Шаляпин бала чактан татар моңнарын ишетеп үскән. Аның иҗатына татар көйләренең йогынтысы зур булган.






Җырчы Казанда беренче тапкыр сәхнәгә чыккан һәм үзенең туган шәһәрен һәрвакыт хөрмәт белән искә алган. Дөньякүләм танылу алганнан соң да, җырчы Казан турында җир йөзендәге иң матур шәһәр дип язган.

Татарстанда ел саен Фёдор Шаляпин исемендәге опера фестивале уза, ә 13 февральдә татарстанлылар җырчының туган көнен билгеләп үтә, Казандагы һәйкәленә чәчәкләр китерә.

КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘР

**Шиһабетдин Мәрҗани** – татар мәгърифәтчесе, үз заманының иң бөек тарихчыларыннан берсе. Ул татарларның белемен күтәрү һәм милли үзаңын үстерү өчен бик күп эшләгән.





**Абдулла Алиш** – татар язучысы, балалар өчен язылган хикәя, шигырь һәм әкиятләр авторы. Бөек Ватан сугышы башлангач, фронтка киткән, үзенең халкын һәм Ватанын саклап һәлак булган. Алиш әсәрләрен берничә буын укучы белә һәм яратып укый.



Алишның «Бикбатыр белән Биккуркак» әкияте геройлары



Алишның «Бал корты һәм Шөпшә» әкияте геройлары



**Пётр Петрович Хузангай** – чуваш шагыйре һәм тәрҗемәчесе. Хузангайның шигырьләре илебез һәм дөнья әдәбиятының алтын фондына кергән һәм 25 телгә тәрҗемә ителгән. Шагыйрь халыклар арасындагы дуслык һәм үзара ихтирамга дан җырлый.



**Андриян Григорьевич Николаев** – дөньядагы беренче космонавтларның берсе. Андриян Николаев космик корабльдә, беренчеләрдән булып, скафандрсыз эшли башлаган, шулай ук беренче фәнни-техник тәҗрибәләрдә катнашкан.



**Флор Иванович Васильев** – удмурт совет шагыйре, удмурт телендә чыккан 7 шигырь-ләр җыентыгы авторы, аларның күбесе дөньяның төрле телләренә тәрҗемә ителгән.




**Ашальчи Оки (Акилина Григорьевна Векшина)** – беренче удмурт шагыйрәсе һәм хатын-кыз язучысы, Бөек Ватан сугышы ветераны, фронт табибы. «Сугышчан хезмәтләре өчен», «Берлинны алган өчен», «Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнгән. Үзенең шигырьләрендә шагыйрә удмурт хатын-кызына, аның сабыр холкына һәм күңел байлыгына дан җырлый.




**Михаил Петрович Девятаев** – мордва (мукшы), гвардия өлкән лейтенанты, Советлар Союзы Герое, бомбардировщикта немец концлагереннан качуны оештырган кыю очучы. Аның батырлыгы турында 2021 елда «Девятаев» фильмы төшерелде.







**Степан Дмитриевич Эрьзя** – мордва (эрзя) совет рәссамы, скульптура остасы. Монументаль скульптуралар иҗат итеп, дөнья-күләм танылу алган.







**Сергей Григорьевич Чавайн** – мари шагыйре, тәрҗемәче һәм драматург, мари әдәбиятына нигез са-лучыларның берсе.

**Яков Андреевич Эшпай** – мари композиторы, оркестр өчен беренче мари инструменталь әсәрләре иҗат итүче. 500 дән артык халык көен язып алган һәм эшкәрткән.



# Халык бәйрәмнәре һәм уеннары

Халык бәйрәмнәре һәр халыкның мәдәниятендә зур урын алып тора.

Бәйрәмнәр кешеләрне берләштерә. Бәйрәм традицияләрен саклау мәдәни мирасны буыннан буынга тапшырырга ярдәм итә. Бәйрәмнәр вакытында кешеләр халык җырларын җырлауда, милли музыка уен коралларында уйнауда, халык биюләрен биюдә үз талантларын ача ала, халык уеннары һәм күңел ачуларында катнашып, өлгерлек һәм зирәклекләрен күрсәтә.

Халык бәйрәмнәрендә кеше туган халкы белән бердәмлекне, үз милли мәдәнияте һәм традицияләренә якынлыгын тоя.

Һәр халык үз традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән аерылып тора. Татарстан халыкларында нинди бәйрәмнәр бар, алар кай яклары белән бер-берсеннән аерыла, кай яклары белән охшаш – шул турыда белик.






# РУС ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ

Рус халкы бай бәйрәм традицияләре белән дан тота. Күп гасырлар элек кешеләр язны каршылауны, кышны озатуны, уңыш җыя башлауны һәм башка мөһим вакыйгаларны мул табыннар һәм күңел ачулар белән билгеләп үткән.

Безнең көннәрдә өлкән буыннан яшь буынга тапшырыла килгән бу традицияләрне халык олылый һәм саклый.

Рус халкының күп бәйрәмнәре арасыннан бигрәк тә Май чабу, Иван Купала, Покров көне һәм, әлбәттә, Каравон яратып бәйрәм итеплә.



Бер генә бәйрәм дә традицион рус музыка уен кораллары – **балалайка**, **гөслә**, **гармунда** уйнаган көйләрдән, аларга кушылып җырланган җырлардан башка узмаган.


# МАЙ ЧАБУ

Май чабу – иң борынгы халык бәйрәмнәренең берсе. Кышны озату, көтеп алынган язны һәм кояшны каршы алу чана шуу, күңелле уеннар һәм әйлән-бәйлән белән билгеләп үтелгән.

Формасы белән кояшны хәтерләткән белен бәйрәм символы булган.

Бәйрәмнең төп вакыйгасы – Май чабу карачкысын яндыру. Аның белән бергә барлык күңелсезлекләр дә янып бетә, дип санаганнар.





Күңелле Май чабу бәйрәмен руслар гына түгел, чувашлар да, удмуртлар һәм марилар да билгеләп үтә.



# КАРАВОН

Каравон рус халык бәйрәме кояш хәрәкәтен символлаштыра торган зур әйлән-бәйләннәре, ярминкәләре, бәйрәм сые тулы мул табыннары белән атаклы. Әйлән-бәйләндә үзенчәлекле «үрдәк» адымы белән йөргәннәр.

# ПОКРОВ КӨНЕ

Покров көне – русларның, көзге кыр эшләре тәмамланып, кышны каршы алуны аңлаткан иң мөһим бәйрәмнәреннән берсе. 14 октябрьдә билгеләп үтелә. «Покров нинди – кыш та шундый», дигәннәр халыкта. Яуган кар җирне язга чаклы каплап тора дип саналган. Бәйрәмнең исеме дә шуннан килеп чыккан.



# ИВАН КУПАЛА

Иван Купала елның иң кыска төне – 6 июльдән 7 сенә каршы төндә үткәрелгән. Бәйрәм вакытында яшьләр учак аркылы сикергән, җырлар җырлаган, әйлән-бәйлән уйнаган. Кызлар такыялар үргән һәм, аларны суга төшереп, киләчәкне юраган. Иван Купалада мунчага барганнар, елга яки күлдә коенганнар, шулай итеп, халык ышанулары буенча, бөтен начарлыктан чистарынганнар.



### «Инеш» рус халык уены



Борынгы заманнардан ук билгеле. Парлар (гадәттә, егет белән кыз) тотынышкан килеш кулларын өскә күтәрәләр һәм бер-бер артлы басалар. Кемгә пар эләкмәгән, шул «инеш»нең уртасыннан бара һәм, үзенә пар сайлап, «инеш»нең башланган урынына баса. Парсыз калганы янәдән, «инеш» эченнән барып, үзенә пар сайлый һәм «инеш» башланган урынга бара. Катнашучыларның саны күбрәк булган саен, уен күңеллерәк бара.

# ТАТАР ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ

Күпмилләтле Татарстанда төрле халыкларның бәйрәмнәре зур колач белән билгеләп үтелә. Алар арасында барлык халыклар катнашында күңелле итеп үткәрелә торганнары да бар. Шундый бәйрәмнәрнең берсе – Сабантуй.



# САБАНТУЙ

Сабантуй – татар халкының иң матур бәйрәме. Аны язгы кыр эшләре беткән хөрмәткә июнь аенда билгеләп үтәләр. Ул күңелле уеннары һәм бәйгеләре, халык күңел ачулары һәм җыр-биюләре белән төрле милләт кешеләрен үзенә тарта, шунлыктан бөтен дөньяга билгеле.

Ат чабышы һәм татарча көрәш традицион рәвештә Сабан туеның төп вакыйгасы санала. Җиңүче батыр төп бүләк – тәкә һәм иң матур сөлгене ала.




# ЖЫЕН

Җыен – татарларның иң борынгы бәйрәмнәреннән берсе. Аны җәй көне, печән өсте башланыр алдыннан үткәргәннәр. Бәйрәм көннәрендә ярминкәләр оештырылган, авыл халкы бер-берсенә кунакка йөрешкән. Кунакларны кырда, чәчәкләр һәм тасмалар белән бизәлгән капка янында, сый белән каршы алганнар. Ә кичен барлык кеше өчен табын әзерләгәннәр.

**«Чүлмәк вату» татар халык уены**

Сабан туенда һәм башка бәйрәмнәр вакытында олысы да, кечесе дә «Аркан тарту», «Капчык киеп йөгерү», «Багана-га менү», «Көянтә белән йөгерү» кебек кызыклы уеннар уйныйлар. Иң күңеллеләреннән берсе – «Чүлмәк вату». Күзләре бәйләнгән катнашучы таяк белән балчык чүлмәк-не ватарга тиеш, ә тамашачылар катнашучыга сугу өчен юнәлешне әйтеп торалар.



# КАРГА БОТКАСЫ

Карга боткасы – язны каршы алу бәйрәме. Борынгы чорларда кешеләр язны канат очларында кара каргалар алып килә дип ышанганнар. Барлык кешегә дә җитсен дип, ботканы зур казанда пешергәннәр. Беренче порцияне, яхшы уңыш булсын дигән теләк белән, җиргә биргәннәр. Икенче өлешне корылык булмасын дип – елгага, өченчесен җылыны өмет итеп – күккә, ә дүртенчесен, язны алып килгән өчен, рәхмәт йөзеннән каргаларга биргәннәр.



Музыкасыз нинди бәйрәм инде ул! Татарлар – җырлы-моңлы халык. Татарларның традицион көйләрен башка халыкларның музыкасы белән бутап булмый. Татар көйләре кабатланмас моңы, күңелгә үтеп керә торган аһәңе һәм үзенчәлекле милли яңгырашы белән аерылып тора.



# КАЗ ӨМӘСЕ

Каз өмәсе татарларның кышкы йолалары арасында аерым урынны алып торган. Күршеләр, кызлар һәм егетләр, берәр нинди эшне өмә белән башкару өчен, бергә җыелганнар. Мәсәлән, бергәләп казлар йолкыганнар һәм шул вакытта аралашканнар.



Традицион татар музыка уен кораллары – **курай**, **тальян гармун** һәм **кубыз.**

# ПИТРАУ

Питрау – традиция буенча җәй уртасында үткәрелә торган керәшен (татарлар составындагы этник төркем) бәйрәме. Питрауга җиләкләр һәм үләннәр җыю гадәте булган. Кешеләр, әгәр дә кырык үләннән торган себерке белән чабынсаң, теләсә кайсы авыруны җиңеп була, дип ышанган. Кичен җырлар җырлаганнар һәм учак аша сикергәннәр.



# ЧУВАШ ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ

Чувашлар үз традицияләрен саклыйлар һәм матур итеп милли бәйрәмнәрен үткәрәләр.

Саварни (чуваш теленнән тәрҗемә иткәндә «май атнасы») яз башында билгеләп үтелә. Бәйрәмгә белен, йомры күмәч, йава – йола печеньесы пешергәннәр, бер-берләренә бүләкләр бирешкәннәр, белен белән сыйланганнар, атта җырлап йөргәннәр, күңел ачканнар. Бәйрәм ахырында карачкыны яндырганнар.



# АКАТУЙ

Акатуй (чуваш теленнән тәрҗемә иткәндә «сабан туе») – чуваш халкының язгы кыр эшләре бетүгә багышланган иң мөһим милли бәйрәмнәренең берсе. Бу көнне чувашлар бер-берсен җәй килү белән котлаган, әйлән-бәйлән оештырган, халык җырлары җырлаган. Хатын-кызлар милли





Чакат һәм шурпа

сыйлар – чакат (эремчек запеканкасы) һәм шурпа (милли аш) пешергән. Ирләр билбаулы көрәш, ат чабышы, көч һәм җитезлек сорый торган башка спорт уеннары оештырган.



Чуваш гөсләсе – **кесле** һәм чуваш сыбызгысы – **шахлич** күңелле милли бәйрәмнәрнең юлдашы булган.



# Уяв

Уяв (чуваш теленнән тәрҗемә иткәндә «саклау») – чувашларның борынгы бәйрәмнәре. Ул печән өстенә кадәр берничә атна дәвам иткән. Бәйрәм исеме аралашу, чуваш халкының бердәмлеге, халык традицияләрен саклау белән бәйле. Бу көннәрдә кешеләр, уңыш булсын дип, дога кылганнар, яшьләр учак тирәли әйлән-бәйлән оештырганнар, җырлар җырлаганнар, халык уеннары уйнаганнар, Уяв чибәрен сайлаганнар.






# СУРХУРИ

Сурхури (чуваш теленнән тәрҗемә иткәндә «сарык аягы») – декабрь ахырында үткәрелә торган борынгы бәйрәм. Бәйрәм атнасында чувашлар, уңыш яхшы булсын дип, йолалар башкарганнар, кунакка йөрешкәннәр, бәйрәм ашы белән сыйланганнар, җырлар җырлаганнар, бер-берсен бәйрәм белән котлаганнар.



## «Сезгә кем?» («Тили-рам?») чуваш халык уены

Ике команда 10–15 метр ара белән бер-берсенә каршы баса. Беренче команда хор белән: «Тили-рам, тили-рам» («Сезгә кем? Сезгә кем?»), – ди. Икенче команда беренче командадагы бер уенчыны атый, ул, йөгереп килеп, икенче команданың кысып тоткан кулларын өзәргә тиеш.

Әгәр йөгереп килүче икенче команданың чылбырын өзсә, ул үз командасына бер уенчыны алып китә. Әгәр йөгерүче чылбырны өзә алмаса, ул дошман командасында кала. Аннары командалар рольләрне алмашалар. Җиңүче команда канат тартканнан соң билгеләнә.



# УДМУРТ ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ

Башка халыклардагы кебек үк, удмуртларның бәйрәмнәре дә һәрвакыт кечесен дә, олысын да бергә җыйган. Бәйрәмнәрдә матур итеп киенү, милли ризыклар әзерләү, күңел ачу, бер-береңә яхшылык теләү кабул ителгән була.

## ВОЙ (ВОЙДЫР)

Вой (Войдыр) – кышны озату. Бәйрәм русларның Май чабу бәйрәменә охшаган: һәрбер өйдә кояш символы булган белен пешергәннәр, аның белән кунакларны сыйлаганнар, үзләре дә ашаганнар. Войдыр вакытында мул ярминкәләр оештырылган, чана шуганнар, җырлаганнар һәм биегәннәр. Ә бәйрәмнең төп вакыйгасы карачкы яндыру булган.



Бәйрәмнәрдә һәрвакыт милли музыка уен кораллары яңгыраган.
**Крезь** (удмурт теленнән тәрҗемә иткәндә «җыр, моң») – рус гөсләсенең «туганы», кыллы, чиртеп уйный торган халык музыка уен коралы.
Ә удмурт скрипкасы – **кубыздан** башка бер генә туй да үтмәгән.



# БЫДЗЫМНУНАЛ

Быдӟымнунал (башка исемнәре: Буӟӟиннал, Великтэм, Акашка, Паска) – удмурт Пасхасы. Төп бәйрәм көнендә, кояш чыкканнан соң, пасха ашы – шыд, табани (юка көлчәләр), ипи пешергәннәр. Аларны изгеләндергәннәр, дога кылганнар, ә аннары табын артына утырганнар. Йорт хуҗасы өстәл янында утырган балаларга түгәрәк буйлап буялган йомырка җибәргән. Пасханың иң күңелле мизгеле йомырка вату булган: үзе бөтен калып, башканыкын ваткан йомырка хуҗасы пасха йомыркасы алган.



# ГЫРОН БЫДТОН

Гырон быдтон (удмурт теленнән тәрҗемә иткәндә «сабан эше тәмамлану») – Татарстандагы иң танылган һәм халык күп җыела торган удмурт бәйрәме. Борынгы заманнарда ул уңыш әйбәт булсын өчен дога кылу һәм җиргә корбан китерүдән башланган, бәйрәм күңел ачулар белән дәвам иткән. Традиция буенча, бәйрәм кунакларын учакта пешкән ботка белән сыйлаганнар. Бөтен җирдә җырлар җырлаганнар, биегәннәр, яшьләр халык күңел ачулары вакытында кызыклы уен һәм бәйгеләрдә көч һәм җитезлек буенча ярышкан.





# ВОЖОДЫР

Вожодыр – 7 гыйнвардан 19 ына кадәр үтә торган бәйрәм. Утырмалар, күрәзәлек итү, битлек кию Вожодырның төп вакыйгалары булган. Битлек кигән кешеләр ишегалларына кереп җырлап йөргән. Йорт хуҗалары аларны тәм-томнар һәм бәлеш белән сыйлаган. Битлек кигән кешеләр бәхет һәм сәламәтлек китерә, дип уйлаганнар.

**«Кубыста йыр» («Кәбестә кәчәне») удмурт халык уены**

Санамыш ярдәмендә ике алып баручыны билгелиләр: Каравылчы һәм Кәбестә. Уенчылар алып баручылардан 2–3 адым ераклыкта басалар. Каравылчы Кәбестәне берничә тапкыр әйләнеп йөгереп чыга да: «Кәбестә өлгерде!» – дип кычкыра. Уенчылар, йөгереп килеп, Кәбестәгә кул белән кагылырга тиешләр. Каравылчы бер кулы белән чүгәләп утырган Кәбестәнең башыннан тота, ә икенче кулы белән уенчыларга орынырга тиеш. Ул, кемгә дә булса орына алса, «Каракны тоттым!» дип кычкыра. Тотылганы – Каравылчы, ә Каравылчы Кәбестә була.



# МОРДВА ХАЛЫКЛАРЫ БӘЙРӘМНӘРЕ

Мордва халык бәйрәмнәре тирән тарихи тамырларга ия. Тантаналар, уңыш җыйганнан соң, язны каршы алганда һәм кешеләр тормышындагы башка мөһим вакыйгалар уңаеннан үткәрелгән. Һәрбер бәйрәмне билгеле бер йолалар озата килә. Халыкның мәдәниятен, милли үзенчәлекләрен саклау өчен, бәйрәм традицияләрен үтәү, аларның мәгънәсен белү бик мөһим.

## МАСЛАНЦЯ (МУКШЫ), ЯКИ МАСТЯ (ЭРЗЯ)

Масланця (мукшы), яки Мастя (эрзя) рус Май чабу бәйрәменә охшаш. Халыкта: «Май чабу бәйрәмен ничек каршылыйсың – елың шулай үтә», – дигәннәр. Шуңа күрә язны каршы алу бәйрәме һәрчак биюләр, Май чабу тавыннан чаналарда шуу һәм, әлбәттә, тәмле белен белән сыйланып, шау-шулы һәм күңелле үткән.



# ОЧИЖИ (МУКШЫ), ЯКИ ИНЕЧИ (ЭРЗЯ)

Очижи (мукшы), яки Инечи (эрзя) (тәрҗемәдә «Бөек көн») – мордва Пасхасы. Бәйрәмгә алдан әзерләнгәннәр. Төп сый: кургине – эремчек яки бәрәңге салынган зур ватрушка, кулич, эремчекле пасха, тормыш һәм аның яңарышы символы – буялган йомырка.

Пасханы гәүдәләндереп, бәйрәмчә киенгән пар – егет белән кыз йортлар буйлап йөргән. Һәр йортта аларны шатлык белән каршы алганнар һәм сыйлаганнар, күчтәнәч биргәннәр.




Бәйрәмнәрдә аска таба киңәеп киткән тар тактага охшаган, кылы астында үгез куыгы булган халык музыка уен коралы – **гайтияма** (мукшы), яки **гайдяма** (эрзя) тавышы астында йола җырлары җырланган.



# БАЛТАЙ

Балтай – мордваларның урман хуҗасы – аюга багышланган борынгы бәйрәмнәре. Бәйрәмнең төп геройлары – өрәңге яфраклары белән бизәлгән берничә кешедән торган «аю гаиләсе». Алар авыл буйлап йөри һәм һәрбер кешегә тынычлык һәм яхшылык тели.

Бәйрәмгә кешеләр бөтен республикадан килә, халык бергәләп бии, җырлар җырлый һәм милли уеннар уйный.



# РОШТУВАНЬ КУД (МУКШЫ), ЯКИ РОШТОВАНЬ КУДО (ЭРЗЯ)



Роштувань куд (мукшы), яки Роштовань кудо (эрзя). Бәйрәмнең исеме тәрҗемәдә «Раштуа ызбасы» дигәнне аңлата. Тантана 25 декабрьдән 7 гыйнварга кадәр сузылган. Аны колядкалар, бер-берсенә яхшылык һәм муллык теләгән йола җырлары, биюләр белән билгеләп үткәннәр. Кулларны өскә күтәреп бию кабул ителгән була, ул кояшка мөрәҗәгатьне һәм агачны символлаштырган. Бодай, арыш, карабодай көлтәләренә карап, уңышны фаразлаганнар: кайсы көлтәдә төне буена бәс күбрәк була, яңа елда шул ашлык уңачак.

**«Ачкыч» мордва уены**

Мордва халык уены «Ачкыч» («Пантемаса» (мукшы), «Панжомнесэ» (эрзя)). Җиргә сызып ясалган квадрат эчендәге алып баручы, почмакларда утыручы уенчыларның берсе янына килеп: «Абый, (апа), ачкыч синдәме?» – дип сорарга тиеш. Тегесе, күршесенә күрсәтеп: «Әнә абыйдан (ападан) сора», – дип җавап бирә. Шул рәвешле алып баручы дүртесен дә әйләнеп чыга. Соңгы кеше: «Уртадан эзлә!» – дип, аны квадрат уртасына җибәрә. Бу вакытта уенчылар тиз генә урыннарын алмашырга тиешләр, ә алып баручы кемнеңдер урынын алырга тырышырга тиеш. Урынсыз калган кеше уенны алып бара.



# МАРИ ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ

Уярня (Май чабу) – мариларның борынгы бәйрәме.

Бәйрәм алдыннан өйне яхшылап җыештырганнар, бәйрәм киемнәрен әзерләгәннәр, атны һәм арбаны тасмалар белән бизәгәннәр. Хуҗабикәләр белен пешергән, ә яшьләр бәйрәм тавы (Уярна вара) төзегән.

Уярня курык – таудан шуу кызыклы күңел ачу гына булмаган. Никадәр ераккарак шуып китә аласың, киндерең шуның кадәр озынрак һәм ныграк булып уңачак, дип санаганнар.





# КУГЕЧЕ

Кугече (Пасха) – кышкы йокыдан уянучы табигатьне олылау бәйрәме. Бәйрәм өстәленә һәрвакыт мари милли ашамлыклары һәм буялган йомырка куелган. Бәйрәм традицияләренең берсе атынчыкта атыну булган. Легенда буенча, мари халкы әлеге атынчык буйлап җиргә төшүче Юмынудырдан килеп чыккан.





**«Йыдал пазар»**
**(«Чабата базары»)**
**мари уены**

Уярня бәйрәмендә уйналган борынгы уен. Тузган чабаталарны җыйганнар, урталай чапканнар һәм күчкә өйгәннәр. Уртасына баулы таяк кадап куйганнар. Алып баручы бауны тоткан һәм күч тирәли йөгергән, ә калган уенчылар аннан чабаталар тотарга тиеш булган. Йөгерүче чабаталарны сакларга һәм «ракларны» тотарга тиеш. Аның тарафыннан тотылган уенчы алып баручы булган.



# СЕМЫК

Семык язгы кыр эшләре тәмамлангач үткәрелгән һәм җәй килүгә багышланган. Бәйрәм вакытында кунакка йөрү, җырлау, яхшы уңыш сорап дога кылу, гөслә һәм сорнай тавышына бию кабул ителгән. Бүгенге көндә Семык – мөмкин булган барлык күңел ачуларга – фольклор ансамбльләре чыгышы, ярминкәләр, халык кул эшләре күргәзмәләренә бай күңелле җәйге бәйрәм.

Яшьләр милли уеннарда һәм спорт ярышларында: канат тарту, капчык сугышы, көянтә белән йөгерү, колгага менү һәм башка күңелле бәйгеләрдә катнаша.



# ШОРЫКЙОЛ

Шорыкйол (мари теленнән тәрҗемә иткәндә «сарык аягы») декабрь яки гыйнварда үткәрелгән. Бәйрәм вакытында гаиләнең иминлеге һәм яхшы уңыш өчен йолалар уздырылган. Бәйрәмнең төп йоласын кызлар һәм егетләр үткәргән. Алар, һәр хуҗалыкка кереп, сарыкларның тәпиләреннән тарткан, шуның белән йорт хайваннарына үрчем теләгән.



Бәйрәмдә музыкантлар аерым хөрмәткә ия булган. Алар күңелле көйләр уйнаган һәм тантананы чын мәгънәсендә матур иткән. Мариларның барлык бәйрәмнәре мари сорнае – **шувыр** авазлары астында үткән. Музыкантлар халык йолалары вакытында – матур озын көйләр, туйларда дәртле бию көйләре уйнаган.



# Милли кухня


Идел буе халыкларының кухнясы бай һәм төрле. Без белгән һәм яраткан ашамлыклар борынгыдан барлыкка килгән. Аларның рәвеше, формасы, рецептларда кулланылган продуктлар билгеле бер йолалар белән бәйле булган. Ашамлык һәм аны ашау аерым бер мәгънә белдергән. Менә, мәсәлән, белен кояшны символлаштырган, ә аны ашау тиздән җылы килүен фаразлаган, ботка муллык символы булган.

Күпчелек ризык аерым бер көннәрдә – халык бәйрәмнәрендә һәм туйларда гына әзерләнгән.

## Рус халык кухнясы


Рус халык кухнясы беленнәре, ашлары һәм бәлешләре белән данлыклы. Озын кышларда кешеләр күп кенә кайнар һәм туклыклы ашамлыклар әзерләгән. Борынгыдан килгән рус ашамлыклары – борщ, солянка, щи гадәти көннәрдә дә, бәйрәмнәрдә дә табынга куелган. Пилмәнне берьюлы күп итеп әзерләгәннәр һәм өйалдында катырганнар.

Рус кухнясы шулай ук алдагы көннәргә дип әзерләнә торган традицион кабымлык рецептларына да бай: тозланган, киптерелгән яшелчә, җиләк-җимешләр, осетрина, койка (холодец), кара һәм кызыл уылдык.



## Белен рецепты

***Продуктлар:***





4 йомырка,

4 аш кашыгы атланмай,

2 стакан сөт,

1 стакан он,

1,5 аш кашыгы шикәр комы,

тоз.














1. Йомырка сарысын атланмай белән тугларга, шуңа 1 стакан сөт, он салырга, тоз өстәп, яхшы итеп болгатырга.
2. 1 стакан сөт салып болгатырга.
3. Аерым савытта йомырка агын шикәр комы белән күпертергә һәм аны камырга салырга.
4. Камырны табага юка катлам итеп агызырга. Белен юка һәм йомшак булачак.



Рус ызбасында төп урынны мич алып торган. Аны туендыручы дип йөрткәннәр: анда төрле ашлар, бәлешләр һәм боткалар пешергәннәр. Мич өстендә салкыннан җылынганнар.



# ТАТАР МИЛЛИ КУХНЯСЫ

Татар милли кухнясының төрлелеге һәм байлыгы турында бөтен дөньяда беләләр.

Татар ашамлыкларыннан иң танылганнары – өчпочмаклар, пәрәмәчләр, кыстыбый, сумса, бавырсак, пироглар (өлеш, бәлеш, гөбәдия), шурпа (итле аш). Һәм, әлбәттә, татар кухнясын чәкчәк, чәлпәк, катлама, кош теле һәм башка татлы ашамлыклардан башка күз алдына да китереп булмый, алардан башка бер генә бәйрәм дә узмый.



## Бәлеш рецепты



***Продуктлар:***
















2,5 стакан он,
ярты стакан каймак,
ярты стакан кефир,
тоз,
3 бәрәңге,
суган,
ярты кило сыер ите,
төелгән кара борыч,
сыер ите шулпасы.

1. Каймак, кефир, бер чеметем тоз һәм онны бергә кушып болгатырга. Камырны 30 минутка сөлге астында калдырырга.
2. Сыер итен, бәрәңге, суганны вак итеп, шакмаклап турарга. Тоз һәм борыч өстәп болгатырга.
3. Бәлешнең капкачы өчен камырның өчтән бер өлешен аерып алырга. Калган өлешен юка итеп җәяргә һәм кырыйлары чыгып торырлык итеп формага урнаштырырга.
4. Камыр җәелгән формага эчлекне салырга. Өстенә түгәрәк итеп җәелгән камырны (капкачны) капларга һәм читләрен чеметеп ябыштырып чыгарга.
5. Капкачның уртасында кечкенә генә тишек ясарга, ә аннары аны түгәрәк камыр кисәге белән капларга.
6. 2 сәгать 30 минут пешерергә. 40 нчы минутта камыр кисәген алып, тишектән бераз шулпа салырга.



Идел буендагы башка халыклар кебек үк, татарлар да кунакчыл булулары белән дан тота. Кунак килү – өйдә мөһим вакыйга. Кунак өчен һәрвакыт табын коралар һәм иң тәмле ризыклар белән сыйлыйлар. Татарлар: «Кунак белән өйгә муллык, бәрәкәт килә», – диләр.




# ЧУВАШ ХАЛЫК КУХНЯСЫ

Чуваш халык кухнясы камыр ашларының төрлелеге белән аерылып тора. Чувашлар ярма, кәбестә, җиләк, яшелчә, эремчек, ит пироглары пешергәннәр.

Эчлеге ит (яки балык), бәрәңге һәм суганнан булган зур пирог – хуплуны камырдан ясалган бизәкләр белән бизиләр.

Пуремеч – эремчек ватрушкасы – һичшиксез, бәйрәм табынына бирелә.



## Хуплу пирогы рецепты

***Продуктлар:***




йомырка,
3 стакан он,
1 чәй кашыгы чүпрә,
1 аш кашыгы шикәр комы,
1 стакан су,
20 г атланмай,
1/4 стакан сөт;
400 г ит,
4 бәрәңге,
суган,
тоз,
кара борыч.

1. Су, сөт, шикәр комы, чүпрә һәм азрак онны бергә кушыгыз. Апараны 30 минутка җылы урынга куегыз.
2. Онның яртысын йомырка һәм апара белән кушыгыз. Он өстәп, камыр басыгыз һәм бер сәгатькә калдырыгыз.
3. Бәрәңге, ит һәм суганны зур булмаган шакмакларга турагыз, атланмай, тоз, борыч кушыгыз һәм болгатыгыз.
4. Камырның зуррак өлешен 0,5 см калынлыкта түгәрәкләп җәегез. Формага куеп, эчлекне салыгыз. Өстен икенче түгәрәк камыр җәймә белән каплагыз һәм кырыйларын чеметеп чыгыгыз. Уртасына зур булмаган тишек ясагыз.
5. 180 градуста кызарганчы пешерегез.


«Хуплу» сүзе чуваш теленнән «ябык ашамлык» дип тәрҗемә ителә. Пирогны ашау бик үзенчәлекле. Башта аның өске өлешен – «капкач»ын ачалар, аннары сусыл эчлеген кашык белән ашыйлар.

## УДМУРТ ХАЛЫК КУХНЯСЫ

Удмуртларда бодай, солы, арыш, борчак һәм киндердән пешерелгән тәмле ашамлыклар күп. Төрле эчлекле пәрәпәч удмурт милли кухнясының иң атаклы ризыгы булып тора.


Шулай ук удмуртларда эчлеге кәбестә, торма, эремчек, гөмбәдән булган, пилмәнгә охшаган кечкенә бөккән – пельнянь бик популяр.






## Пәрәмәч рецепты

***Продуктлар:***





2 стакан кефир,

1/3 стакан
үсемлек мае,







1 йомырка, сода,

3 стакан арыш оны,

бер чеметем тоз
һәм шикәр комы (камыр өчен);







бәрәңге боламыгы,
фарш яки гөмбә,

сөт, йомырка
(эчлек өчен).

1. Арыш оныннан камыр басыгыз һәм зур булмаган түгәрәкләр ясагыз.
2. Аларны җәегез һәм читләрен күтәртеп бөгеп чыгыгыз.
3. Урталарына эчлек (бәрәңге боламыгы, фарш яки гөмбә) салыгыз.
4. Йомырканы сөт белән бутагыз һәм килеп чыккан катнашманы эчлеккә агызыгыз.
5. Пәрәмәчләрне 20 минутка 180 градуслы мичкә куегыз.





МИЛЛИ КУХНЯ

# МОРДВА МИЛЛИ КУХНЯСЫ


Мордва милли кухнясы элеккеге вакытларда, нигездә, тары, арпа, ясмык, борчак һәм башка ярмадан пешерелгән боткалардан, бодай белененнән һәм сөт ризыкларыннан торган. Алдагы көннәргә дип, гөмбә, кәбестә тозлаганнар.

«Аю тәпие» («Офтонь мадят» (мукшы), «Овтонь лапат» (эрзя)) – арыш сохариеннан гыйбарәт кәтлит – иң үзенчәлекле ашамлыкларның берсе.




Эрзя һәм мукшы халыклары оста аучылар булган, шуңа күрә өстәлгә еш кына киек ите куелган.

## «Аю тәпие» ризыгы рецепты



***Продуктлар:***





300 г сыер бавыры,
300 г ит фаршы,
бер баш суган,
2 йомырка,
төелгән кара борыч,
тоз,
кәтлитләрне әвәләү өчен бераз он,
ак ипидән сохари.










1. Бавырны вакларга.
2. Туралган суган һәм йомырка, чыгарылган фарш кушып болгатырга.
3. Тоз һәм борыч өстәргә.
4. Кәтлитләрне әвәләп ясарга.
5. Һәрберсен башта – онда, аннары йомырка һәм сохарида әвәләргә.
6. Кәтлитләрне, әзер булганчы, майда кыздырырга.



# МАРИ МИЛЛИ КУХНЯСЫ

Мари милли кухнясы урман нигъмәтләре – һәртөрле ит, җиләк, гөмбә, үләннәр, балдан ясалган күптөрле ашамлыклары белән аерылып тора.

Мари хуҗабикәләре – оннан (төрле эчлекле кабартмалар, катламлы команмелна белене), ярмадан ашамлыклар һәм һәртөрле ашлар пешерүдә осталар. Мәсәлән, чукмарлы (пешкән камыр кисәкләре), борчак һәм гөмбәле лашка ашы.







Мариларда бәрәңгене «икенче икмәк» дип атыйлар. Бәрәңгедән әзерләнгән ашамлыклар буенча мари кухнясы, мөгаен, белорус кухнясыннан гына калышадыр.

## Щыл подкогыльо (суда пешкән итле бөккән) рецепты





***Продуктлар:***

1 стакан он,

1/6 данә йомырка,

50 шәр г дуңгыз
һәм бозау ите,

суган,

1 аш кашыгы
атланмай,

кара борыч,
тоз.











1. Йомырка, он һәм тоздан төче камыр басарга.
2. Камырны юка итеп җәяргә.
3. Уртасына эчлекне салырга.

Эчлек өчен:

4. Чи итне турарга.
5. Суганны вакларга.
6. Ит һәм суганны кушып болгатырга, тоз һәм борыч сибәргә.



7. Ярымай формасында бөккәннәр ясарга, матур итеп чеметепябыштырып куярга.
8. Бөккәннәрне кайнап торган тозлы суда пешерергә.
9. Май сибәргә.

Кайнар килеш бирергә.

# ЙОМГАКЛАУ

Кадерле дустым! Без республиканың иң күп санлы алты халкының искиткеч мәдәнияте дөньясына сәяхәтебезне тәмамладык.

Китапны укыганнан соң, син рус, татар, чуваш, удмурт, мордва һәм мари халыкларының мәдәнияте, традицияләре турында яңа белемнәр алдың. Хәзер син төрле халыкларның милли костюмнарына, аш-су, тел, бәйрәмнәренә хас үзенчәлекләрне беләсең. Гореф-гадәт-



ләр һәм тарих кебек саклана торган мәкальләрдәге халык зирәклеге белән дә таныштың. Моннан тыш, син кече ватаныбыз – Татарстанда туып үскән күренекле шәхесләр турында укыдың. Аларның фидакарь тормыш юлы сиңа үрнәк булып хезмәт итсен.

Ата-бабаларың турындагы хәтерне һәм безнең күпмилләтле халкыбызның уникаль мирасын сакла.

Уңышлар сиңа, кадерле дустым!



# Эчтәлек




Милли бизәкләр
һәм орнаментлар ..................... 4



Милли
киемнәр ................................ 20




Милли телләр
һәм әдәбият ......................... 34



Күренекле
шәхесләр ............................. 48



Халык бәйрәмнәре
һәм уеннары ........................ 54



Милли
кухня ................................... 80

# ТАТАРСТАН. БЕЗ БЕРГӘ
# ТАТАРСТАН. МЫ ВМЕСТЕ


**Художественно-просветительское издание для детей**
**(на татарском и русском языках)**

Автор проекта
**Марат Ганиев**

Руководитель проекта
**Азат Ганиев**

Главный редактор
**Гульнара Головина**

Литературная редакция:
**Алсу Низамеева, Елизавета Семенская,**
**Фаниса Макарова, Зухра Фасхиева**

Художники-иллюстраторы:
**Евгения Кобелева, Елена Бутрова,**
**Анна Гаранина, Елизавета Семенская**

Дизайн
**Дмитрий Гиацинтов**

Графическая вёрстка
**Елена Шарапова**

Музыкальная редакция:
**Мария Сергеева,**
**Рафаэль Бахтиозин**

Руководитель IT отдела
**Дамир Бариев**

Технический директор
**Ильдар Низаметдинов**

Рецензент
**Расима Шамсутдинова**

Консультанты:
**Ляйсан Низамова,**
**Ирек Шарипов**

Фактологические материалы
предоставлены
**Ассамблеей народов Татарстана**
**и Домом Дружбы народов Татарстана**

Эксперты культурно-этнографического контента:
**Людмила Мусихина**,
заместитель председателя Совета
РОО «Национально-культурная автономия
марийцев Республики Татарстан»,
председатель МОО «Национально-
культурная автономия марийцев
Республики Татарстан»

**Сильвия Чаркина**,
заместитель председателя
РОО «Чувашская национально-культурная
автономия в Республике Татарстан»

**Наталья Сабитова**,
руководитель РОО «Национально-
культурная автономия мордвы
Республики Татарстан»

**Павел Александров**,
заведующий отделом развития народного
творчества ГБУ «Ресурсный центр внедрения
инноваций и сохранения традиций в сфере
культуры Республики Татарстан»

**Любовь Тукаева**,
руководитель отдела этнокультурной
деятельности Дома Дружбы народов Татарстана

**Татарское детское издательство**
Редакция Гульнары Головиной

420124, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
www.tdpress.ru

Подписано в печать 23.11.2022
Печать офсетная. Тираж 8000 экз. Заказ №
Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных
Татарским детским издательством материалов в типографии филиала
АО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идель-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

# ИДЕЛ БУЕ БАТЫРЛАРЫ

Татар, рус, чуваш, мари, мордва, удмурт халыкларының әкиятләренә нигезләнеп

**АТӐЛ ПАТТӐРӖСЕМ • ВОЛЖСКИЙ ОНАР**

волжскиебогатыри.рф


КИТАП






## КАМЫР-БАТЫР

Татар халык әкиятләре мотивлары буенча татар һәм рус телләрендә.



## ВОЛЬГА

Рус халык әкиятләре мотивлары буенча татар һәм рус телләрендә.



## ИВАН-БАТЫР • ЙӐВАН ПАТТӐР

Чуваш халык әкиятләре мотивлары буенча татар, рус һәм чуваш телләрендә.



## МАРШАН

Мари халык әкиятләре мотивлары буенча татар, рус һәм мари телләрендә.



## САБАН

Мордва халык әкиятләре мотивлары буенча татар, рус, эрзя һәм мукшы телләрендә.



## СЕЛТА

Удмурт халык әкиятләре мотивлары буенча татар, рус һәм удмурт телләрендә.



БЕЗ БЕРГӘ • ТАТАРСТАН • БЕЗ БЕРГӘ • ТАТАРСТАН • БЕЗ БЕРГӘ • ТАТАРСТАН • БЕЗ БЕРГӘ • ТАТАРСТАН •

Татар, рус, чуваш, мари, мордва, удмурт халыкларының әкиятләренә нигезләнеп

# ИДЕЛ БУЕ БАТЫРЛАРЫ

**ВОЛЖСКИЙ БАТЫРЪЁС ● РАВЧИРЕНЬ МАРАЛЯТ**










**МУЛЬТФИЛЬМНАР** - - ->



волжскиебогатыри.рф

www.без-берге.рф

ISBN 978-5-6046009-4-8

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТ

6+

© Татарское детское издательство, 2022
www.tdpress.ru